# Татарстан Республикасы
# ЗАКОНЫ

**«2001 елга Татарстан Республикасынын бюджет системасы турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү хакында**

**1 статья**. «2001 елга Татарстан Республикасының бюджет системасы турында» 2000 елның 19 декабрендәге 512 номерлы Татарстан Республикасы Законына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2000, № 12 (10), (1 өлеш)) түбәндәге үзгәрешләрне һәм өстәмәләрне кертергә:

1. 1 статьяның беренче өлешен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«**1 статья.** 2001 елга Татарстан Республикасының республика бюджетын керемнәр буенча 33082119 мең сум һәм чыгымнар буенча 34723470 мең сум күләмендә расларга.».

2. 16 статьяның 4 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

| | |
|---|---|
| «4. Кайтарып алынмый торган акча күчерүләр | 12866061 |
| Бүтән дәрәҗәләрдәге бюджетлардан | 12866061 |
| Дотацияләр | 11976180 |
| Компенсацияләр фонды | 708151 |
| - «Россия Федерациясендә инвалидларны социаль яклау турында» Федераль законны гамәлгә ашыру өчен субсидияләр | 192072 |
| - «Балалары булган гражданнарга дәүләт пособиеләре турында» Федераль законны гамәлгә ашыру өчен субвенцияләр | 516079 |
| Юл хуҗалыгына дәүләт ярдәме | 31730 |
| - юл хуҗалыгын финанслауга субвенцияләр һәм субсидияләр | 31730 |
| шулардан: | |
| гомуми кулланылыштагы автомобиль юллары челтәренә кертелергә тиешле авыл юлларын норма хәленә китерү өчен Федераль бюджетның өстәмә керемнәре исәбенә территория | 25000 |

юл фондларын төзү тәртибен үзгәртүгә бәйле рәвештә Россия Федерациясе субъектлары бюджетларынын югалтуын компенсацияләү өчен 150000».

3. Түбәндәге эчтәлекле 22[1] статья өстәргә:

**«22[1] статья**. «2001 елга федераль бюджет турында» 2000 елның 27 декабрендәге 150-ФЗ номерлы Федераль законның 43 статьясы һәм «Казан шәһәренең тарихи үзәген саклау һәм үстерү» федераль максатчыл программа турында» 2001 елның 14 мартындагы 180 номерлы Россия Федерациясе Хөкүмәте карары нигезендә әлеге Законның 4 нче кушымтасы буенча 2001 елга Татарстан Республикасы республика бюджеты чыгымнарынын ведомство структурасындагы чыгымнарны финанслау өчен федераль бюджеттан 12157910 сум җибәрергә.».

4. 4 нче кушымтаны өстәргә (кушымта итеп бирелә).

**2 статья.** Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Президенты М.Ш.Шәймиев

Казан шәһәре,
2002 елның 17 гыйнвары
№ I288